ISSN 0868-4545

№ 5. 2010

САЛАВАТ КҮПЕРЕ

Балалар журналы · Детский журнал · Children's magazine







Җиңү бәйрәме белән котлыйбыз!

С праздником Великой Победы!

Congratulations on Victory Day!

1945-2010

САЛАВАТ КҮПЕРЕ
балалар журналы · детский журнал · children's magazine
№5(242) — 2010
Журнал 1990 елның
март аеннан бирле чыга.
Журнал выходит
с марта 1990 года.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир
урынбасары
Зилә ЯЗ
Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН
Бүлек мөхәррирләре
Нәфис ИСХАКОВ
Римма ШӘЙДУЛЛИНА
Луиза ЯНСУАР
Бизәлеш мөхәррире
Әлфия ЙОСЫПОВА
Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА
Исәп-хисапчы
Рәмзия САЛИХ

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Басарга кул куелды 4.05.2010 ел.
Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Гарнитура – Футурис. Офсет ысулы белән басыла. Заказ О-512.
Тираж 11250 данә.

Журналны гамәлгә куючы – «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте.

Тираж сертификацияләнгән.
Бәясе килешү буенча.
Индекс 73953.
Санны әзерләүчеләр: З. Хөснияр, Л. Лерон, Ф. Муллахмәт, З. Яз, М. Галиев, З. Вакказова, Р. Шәйдуллина.

Безнең адрес: 420012, Казан ш., Мөштәри ур., 14 нче йорт.
Тел.: 236-61-98, 236-00-81, 236-61-97, 236-30-01
E-mail: salavatkupere@mail.ru

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 321 номер белән 1994 елның 4 февралендә теркәлде.

«Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.

Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.



Тышлыкта – Диләрә НӘҮРҮЗОВА рәсеме (йолдыз эчендә – укучыбыз иҗаты)

Бу санда:

2 Кызыл таҗлы ромашка сагышы... М.Җәлил шигырен татар, рус һәм инглиз телләрендә укы.

5 Җиңүчеләребезгә бүләк – открытка ясыйбыз.

8 Ышансаң-ышан, ышанмасаң-ышанма! З.Хөснияр салават күпере төсендәге кошны күргән!

12 *Башкатыргычлар* – Мульт-фильм геройлары нигә Шалайга үпкәләгән?

13 *Мин мәктәптә укыйм* – Әкиятләр тәмам буталып беткән! Ярдәм ит!

14 *Комикс* – Л.Лерон Барабашка хикмәтләрен ача! Ниһаять!

16 *Яшь компьютерчы* – «Бастыру-чы» белән танышабыз.

17 *Мин бит бу!* – Яңа йөзләр – яңа йолдызлар!

18 Яраткан журналыңа язылмыйча калма!

© «Салават күпере», 2010 ел

Бер минутка тын калыйк...

– Яраларың һаман сызлыймы,
Галиулла абый?
– Юк, энем. Яралар күптән сызламый инде.
– Сиңа нинди ярдәм күрсәтик соң,
Галиулла абый?
– Миңа берни дә кирәкми, энем, рәхмәт!
– Син сугыш ветераны бит, без сине хөрмәтләргә тиеш. Иә, әйт инде, сиңа яхшы булсын өчен нәрсә эшлик соң?
– Минем үземә берни дә кирәкми, энем, рәхмәт! Әйдәгез, иң яхшысы сугышта баш салганнарның рухы каршында бер минутка тын калыйк. Һәркем үз күңеленнән аларга карата хөрмәт хисе кичерсен.

Рәссам Элфия ЙОСЫПОВА

Муса ҖӘЛИЛ

Кызыл ромашка

ИРТӘНГЕ ТАҢ НУРЫННАН
УЯНДЫ РОМАШКАЛАР.
ЕЛМАЕП, ХӘЛ СОРАШЫП,
КҮЗГӘ-КҮЗ КАРАШТЫЛАР.

НАЗЛАДЫ ҖИЛ АЛАРНЫ
ТИБРӘТЕП АК ЧУКЛАРЫН,
ТАҢ СИПТЕ ӨСЛӘРЕНӘ
ХУШ ИСЛЕ САФ ЧЫКЛАРЫН.

ЧӘЧКӘЛӘР, КӘЕФЛӘНЕП,
ҖАЙ ГЫНА СЕЛКЕНДЕЛӘР.
ҺӘМ КИНӘТ ШУНДА ГАҖӘП
БЕР ЯҢА ХӘЛ КҮРДЕЛӘР.

ЕРАК ТҮГЕЛ МОҢАЕП
УТЫРА РОМАШКА КЫЗЫ,
ТИК ЧУКЛАРЫ АК ТҮГЕЛ,
КАН ШИКЕЛЛЕ КЫП-КЫЗЫЛ.

РОМАШКАЛАР БАР ДА АК,
АЕРЫЛМЫЙ БЕР-БЕРЕННӘН;
НИЧЕК БОЛАЙ БЕРҮЗЕ
УЛ КЫЗЫЛДАН КИЕНГӘН?

ӘЙТТЕЛӘР:
«СИН, СЕҢЕЛКӘЙ,
НИК ҮЗГӘРДЕҢ?
НИШЛӘДЕҢ?
НИГӘ КЫЗЫЛ ЧУКЛАРЫҢ?
НИДӘН АЛСУ ТӨСЛӘРЕҢ?»

ӘЙТТЕ КЫЗЫЛ РОМАШКА:
«ТӨНЛӘ МИНЕМ ЯНЫМА
ЯТЫП БАТЫР СУГЫШЧЫ
АТТЫ ДОШМАННАРЫНА.

УЛ БЕРҮЗЕ СУГЫШТЫ
УНБИШ УКЧЫГА КАРШЫ;
ЧИГЕНМӘДЕ, ТИК ТАҢДА
ЯРАЛАНДЫ КУЛБАШЫ.

АНЫҢ БАТЫР АЛ КАНЫ
ТАМДЫ МИНЕМ ЧУКЛАРГА.
МИНЕМ КЫЗЫЛ КҮЛМӘГЕМ
БИК ОХШАДЫ ЧУЛПАНГА.

ЕГЕТ КИТТЕ, МИН КАЛДЫМ
КАНЫН САКЛАП ЧУГЫМДА,
КӨН ДӘ АНЫ САГЫНЫП
БАЛКЫЙМ МИН ТАҢ НУРЫНДА».

ИЮЛЬ, 1942.

Musa Jalil

Red daisy

DAISIES WOKE UP
IN EARLY MORNING.
GREETED EACH OTHER
AS IF THEY WERE SMILING.

PETALS SWAYED
WIND BLEW ON THEM.
WITH THE MORNING DEW
DAWN WASHED THEM.

DAISIES SWING,
THEY ARE ENJOYING.
SUDDENLY THEY ALL
GLANCED TO OTHER TURN.

THEY SAW ANOTHER DAISY
NOT LIKE OTHER GIRLS
SHE WAS SAD AND UPSET.
NOT WEAR WHITE DRESS.

ALL GIRLS WERE AS SNOW
ALL THEY WERE ALIKE.
THIS DAISY WAS IN RED.
SHE ONLY WAS UNLIKE.

DAISIES WANTED KNOW
WHAT'S HAPPENED WITH THE GIRL.
WHY SHE IS IN RED
LOOKING VERY SAD.

LAST NIGHT A CRUEL BATTLE
WAS HAPPENED NEAR GIRL.
BRAVE SOLDIER FOUGHT HERE,
WITHOUT A FRIEND. HE WAS ALONE.

THEY WERE FIFTEEN. HE WAS ALONE.
IN THE MORNING THEY FOUGHT LONG.
HE WOUNDED SHOULDER –
MY FEARLESS SOLDIER.

HE LEFT ON THE DAWN.
I WASHED IN HIS BLOOD.
AS CHULPAN I WILL BURN.
AND GRIEVE FOR HIM ALONE.

JULY, 1942.

Талия УСМАНОВА тәрҗемәсе

Муса ДЖАЛИЛЬ

Красная ромашка

ЛУЧ ПОЛЯНУ ОСВЕТИЛ
И РОМАШКИ РАЗБУДИЛ:
УЛЫБНУЛИСЬ, ПОТЯНУЛИСЬ,
МЕЖ СОБОЙ ПЕРЕГЛЯНУЛИСЬ.

ВЕТЕРОК ИХ ПРИЛАСКАЛ,
ЛЕПЕСТКИ ЗАКОЛЫХАЛ,
ИХ ЗАРЯ УМЫЛА ЧИСТОЙ
СВЕЖЕЮ РОСОЙ ДУШИСТОЙ.

ТАК КАЧАЮТСЯ ОНИ,
НАСЛАЖДАЮТСЯ ОНИ.
ВДРУГ РОМАШКИ ВСТРЕПЕНУЛИСЬ,
ВСЕ К ПОДРУЖКЕ ПОВЕРНУЛИСЬ.

ЭТА ДЕВОЧКА БЫЛА
НЕ КАК ВСЕ ЦВЕТЫ БЕЛА:
ВСЕ РОМАШКИ, КАК РОМАШКИ,
НОСЯТ БЕЛЫЕ РУБАШКИ.

ВСЕ — КАК СНЕГ, ОНА ОДНА,
СЛОВНО КРОВЬ, БЫЛА КРАСНА.
ВСЯ ПОЛЯНА К НЕЙ ТЕСНИЛАСЬ:
— ПОЧЕМУ ТЫ ИЗМЕНИЛАСЬ?

— ГДЕ ВЗЯЛА ТЫ ЭТОТ ЦВЕТ? —
А ПОДРУЖКА ИМ В ОТВЕТ:
— ВОТ КАКОЕ ВЫШЛО ДЕЛО.
НОЧЬЮ БИТВА ЗДЕСЬ КИПЕЛА,

И ПЛЕЧО В ПЛЕЧО СО МНОЙ
ТУТ ЛЕЖАЛ БОЕЦ-ГЕРОЙ.
ОН С ВРАГАМИ СТАЛ СРАЖАТЬСЯ,
ОН ОДИН, А ИХ ПЯТНАДЦАТЬ.

ОН ИХ БИЛ, НЕ ОТСТУПИЛ,
ТОЛЬКО УТРОМ РАНЕН БЫЛ.
КРОВЬ ИЗ РАНЫ ЗАСТРУИЛАСЬ,
Я В КРОВИ ЕГО УМЫЛАСЬ.

ОН УШЕЛ, ЕГО ЗДЕСЬ НЕТ —
МНЕ ОДНОЙ ВСТРЕЧАТЬ РАССВЕТ.
И ТЕПЕРЬ, ПО НЕМ ГОРЮЯ,
КАК ЧУЛПАН-ЗВЕЗДА ГОРЮ Я.

ИЮЛЬ, 1942.

Рәссам Евгения ГЛЕБАШЕВА

Дускай, әйдә, бергәләшеп ветераннарыбызга бүләк-открытка ясыйк.
Журналның әлеге битен иплəп кенә кисеп алырга һәм икегә бөкләргә кирәк.



Бәйрәм белән!

Ускәчтен дә дошман булмыйк беребез дә.
«Дуслык» сүзе булсын безнең телебездә.
Шатлык кына таратыйк без өйдән өйгә,
Тик кунакка йөрешик без илдән илгә!

«Тынычлык» дип барыгыз да сез дәшегез,
Бөтендөнья балалары, берләшегез!
Килер безгә гомумбәхет дәвере бер.
Җир бомбасыз Җир шарына әверелер!

Роберт Миңнуллин

Рәссам Әлфия ЙОСЫПОВА



Хөрмәтле ветеран!



Былбыл

ГАБДЕЛКАЮМОВА Айзиләнең
хаты һәм рәсеме.
Казан шәһәрендәге 5 нче гимназиянең
6 «Б» сыйныфы укучысы.



Бөек Ватан сугышы еллары... Бу елларны, вакыйгаларны без китаплардан укып, кинолардан карап кына беләбез. Күпме яшь-яшь егет һәм кызлар, абыйлар һәм апалар, бала-чагалар сугыш кырларында мәңгелеккә ятып калган.

Солдатларыбыз зур батырлыклар эшләгән. Безнең киләчәгебез өчен алар үз гомерләрен кызганмаганнар. Бик зур рәхмәт Сезгә!

Әмма тылда калганнар да зур батырлыклар күрсәткән. Хатын-кызлар сугыш вакытында күп авырлыклар күргәннәр. Ләкин ач-ялангач тормыш, авыр хезмәт аларны куркытмаган. Завод-фабрикаларда да, кыр-басуларда да тырышып эшләгәннәр.

Сугыш башланганда минем әбиемә 18 яшь булган. Ул да җиңү көнен якынайту өчен барсын эшләгән. Җәй көне ул кырда урак урган, кыш көне урманда агач кискән, 30 километр ераклыктагы район үзәгеннән чәчүлек орлык та ташыган. Җиңү сүзен зарыгып көткән.

Әбиемнең сугыш елларында эшләгән олы һәм авыр хезмәтләрен хөкүмәтебез югары бәяләгән. Аны медаль белән бүләкләгәннәр һәм хезмәт ветераны исеме биргәннәр.



Нияз ИБӘТУЛЛИН
5 нче гимназиянең
2 «А» сыйныфы укучысы.



Салават күпере әкияте

Җәйге яңгырдан соң күктә, искиткеч матур булып, Салават күпере кабынды. Аның матурлыгын күрсәң син! Исең-акылың китәр иде менә, билләһи! Җитмеш төрле төсләр белән җем-җем уйный ул!!!

Иң беренче булып, Салават күперен капкадан чыккан әбекәй күреп алды. Ул да бу матурлыкка чак кына хуштан язмады! Тик аның кәҗәсенә үлән йолкыйсы бар иде. Ул дымлы җиргә таба иелде. Һәм Салават күперенең аллы-гөлле канатлы, гаҗәп матур Кошка әверелгәнен күрми калды. Әлеге Кош үзенең матур, йомшак канатлары белән әбекәйнең аркасыннан да сыйпап китте әле. Шуннан соң, бар болынны төрледән-төрле төсләргә манып, күктә очып әйләнде.

Менә ишектән бер нәни кызчык килеп чыкты. Салават күпере, балкып, һаман күктә эленеп тора иде әле. Кызчык чыңлап көлеп җибәрде дә, дымлы үләннәр өстеннән Салават күперенә таба йөгерде. Күк йөзендә эленеп торган матурлыкка каршы йөгерде кыз бала... Шулчак салават күпере янә зиннәтле каурыйлы теге кошка әйләнде. Аннан соң кызчыкны үзе белән очыртып алып китте. Кош белән бергәләп зәңгәр күктә йөзүләре шулчаклы рәхәт иде!

Күк-бишектә рәхәтләнеп беркавым тирбәлгәннән соң, матур Кош кызчыкны кире үлән өстенә бастырды.

— Кызым, нигә юеш үләндә йөрисең? Салкын тидерәсең бит хәзер! — дип шелтәләде әбисе, оныкачын күреп.

— Әбием, әбекәй! Беләсеңме, мин үләндә йөрмәдем, мин очтым бит! Салават күпере сыман Кош болын буйлап очыртты мине! — дип җавап бирде кызчык.

— Ә хәзер кайда соң ул син әйткән матур кош?

— Монда, — дип пышылдады кызчык һәм нәни кулын йөрәк турысына куйды.



УКУЧЫМ!

Ә хәзер синең игьтибарга «Җәйге бәйге» тәкьдим итәбез. Октябрь аенда бәйгегә нәтиҗә ясарбыз.

БӘЙГЕНЕҢ СОРАУЛАРЫ:

Ни өчен матур Кош әбинең күзенә күренмәгән?

Матурлыкка сокланырга өйрәнергә мөмкинме?

«Салават күпере» журналы белән күктәге салават күпере арысында нинди аерма һәм нинди охшашлык бар?

Ихтирам белән,
Зиннур абый ХӨСНИЯР

Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Җир шарын саклаг

Җиңү көне. Әби елый,
Әни аңа кушыла.
Әтинең дә кәефе юк,
Алмыймын берни кыла.

Сугышларда ятып калган
Бабамны уйлый әби.
Ятим үскән икесе дә
Әнием белән әти.

Ике күрше булган алар —
Дуслар булган тормышта.
Икесе дә берүк көнне
Чыгып киткән сугышка.

Хәбәр түгел, каберләр юк
Чәчәк салырга барып.
Хәбәрсез югалганнар,
Җиңүне яулап алып.



Каберләрен белсәк тә,
Тынычланырлар иде.
Кайда баш салганнар да,
Туфраклары кем иле.

Зиннур ХӨСНИЯР

Калган бабам



Мин Хыялый Хәйрүш бит,
Хыялга бай малай мин.
Хыяллана белмәгәннәр
Тутыккан бер калай, — ди.

Хыяланыйк әле бергә
Андый бәхет татыган ди
Тагын кемгә!
Бабамнарның каберләрен
Табыйк әти-әнигә
Һәм дә безнең әбигә!

Ясадым бер машина —
Машинамы — очкыч ул!
Бик сәер ул, серле ул,
Тизлеге ни — очкын ул!

Дөнья буйлап сәяхәткә
Чыгып китәм әле мин.
Бабамнарның каберенә
Чәчәк салып,
Әйләнепләр кайтам мин!

Кара карга юлны белә —
Аны штурман итәм.
Әтәч тә ризалашты —
Үзем булдым капитан!

Кабыздык машинаны да
Көнбатышка юл алдык.
Казан халкы кул болгап
Хәерле юл теләп калды.

Ауропага килеп җиттек —
Менә Польша, Венгрстан.
Бик зур икән Җир шары —
Шәп күренә ул өстән.

Әтәч кулында карта —
Юлны карап бара ул.
Кара карга киңәш бирә —
Моннан очып кайткан ул.

Исем китеп карап барам,
Бик зур шул Җир шары.
Кайда чәчәкләр үсә,
Кайда яткан ак кары...

Килеп җиттек Ауропага —
Сөйләшү гел инглизчә.
Мин тик аптырап йөрим,
Бер телне дә белмичә.

Кара карга күп тел белә,
Немецча да сөйләшә.
Һәркайсын сатып җибәрә
Әгәр бик тә кирәксә!

Туганнар каберлеген без
Өзләп таптык тиз генә.
Ике бабам шушында дип,
Мин беркеттем күңелгә.

Бер уч туфрак алып салдым,
Үзем белән кайтырга.
Ә бабалар калды инде
Мәңге шунда ятарга...

Илләр буйлап оча торгач,
Уй килде миңа тагын:
Бабаларым бу сугышта
Саклап калган Җир шарын!...




Рәссам Светлана ИБРАҺИМОВА





Башкатыргычлар

Шалайның иң яраткан ы — мультфильмнар. Ләкин бер көнне ул, әнисенең сүзен тыңламыйча, дәресләрен әзерләү урынына мультфильмнар карап утырды. Шуннан соң үпкәләде дә инде аңа мультфильм геройлары — тәмам буталышып беттеләр. Шалай, хатасын аңлап, дәресләрен әзерләп куйды, әнисеннән дә гафу үтенде... Әйдә, бергәләп Шалай дуска ярдәм итик!



Әлеге шакмакчыкларда саннар төшеп калган. Игътибарлы бул, горизонталь һәм вертикаль юлларда кабатланмыйча 1 дән 9 га кадәр саннар сыешып бетәргә тиеш.

		3	6		2	5	1	
6	2	5	1		3	9		
9							2	
2		7		1				
1	5		2			3		4
8	6		5		1	7		
3	8	6	9	2		4	5	
5			3	4	1		8	
4	7	1		6	5	2		

	7	5		8				6
1	4	6			7	9		
			9	1		7		
			1	7				2
7	2	4	8					
6					2		7	5
	9	7	2					
3				5	4	2	9	
5	6	2				4	8	



Сәхифәне
Римма Шәйдуллина
алып бара

Язгы җитез җил, кояш нурлары белән җылынып, урамда уйнаклап йөри. Елмайның бүлмә тәрәзәсен дә каккан була, урамга чакыра. Кинәт «шап-шоп» тәрәзәне катырак какты да, киң итеп ачып, бүлмәгә дә кереп җитте. Елмайның өстәлендәге тәртипне бозды, «Уку китабы»н идәнгә үк бәреп төшерде. Шул вакыт бөтен әкият геройлары буталышып беттеләр. Елмай «Өч кыз», «Хәйләгә каршы хәйлә» һәм «Кәҗә белән бүре» әкиятләрендәге геройларны, исенә төшереп, бергә җыя алмады...

Дускай, һичшиксез, син бу әкиятләр белән уку дәресендә танышкансыңдыр! Елмайга ярдәм итеп кара әле. Бу өч әкиятне исеңә төшереп сөйлә һәм рәсемнәрдәге геройларны төрле төстәге каләмнәр белән тоташтырып чык.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Ләбиб ЛЕРОН

БАРАБАШКА ХИКМӘТЛӘРЕ

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ




Алмаз! Кемдер минем
чәчемнән тарта!


Минем колакларны
да кемдер боргалый!


Ха-ха-ха!
Ха-ха-ха!
Ха-ха-ха!


Әкәмәт!
Кем эше бу?


Минем эш бу!


Йокың тәмле булды-
мы, Алмаз?



ПРИНТЕР турында яки «БАСТЫРУЧЫ»

Сәхифәне Зөлфия Вакказова алып бара

Күбегезнең принтер турында ишеткәне бардыр. Ул синең компьютерыңдагы текстны кәгазьгә бастырып чыгара. Реферат, контроль эш яки яраткан фотосурәт синең кулыңа эләксен өчен принтер кирәк.

Әгәр айга бер кәгазь чыгарасың икән, бу очракта гади принтер да ярап тора, әгәр инде мәктәпнең көндәлек гәзитен эшлисең икән, яхшырагын сайларга кирәк.

Принтерлар бастыру тизлеге буенча аерыла. Кайберләре бер кәгазьне озак чыгара, икенчеләре — «эһ» дигәнче.

Шулай ук принтерларның аклы-каралы һәм төсле итеп бастыра торганы бар. Ә хәзер принтерларның төрен ачыклыйк:

1. Энәле принтер (матричный принтер). Басылу шактый начар булып, шаулап эшләсә дә, мондый принтерга буяу салырга кирәкми.
2. Агынтылы принтер (струйный принтер). Текстны кәгазьгә буяуны сиптереп бастыра. Шуңа буяу савытын еш алыштырып торырга кирәк.
3. Лазерлы принтер (лазерный принтер). Кәгазьне бик сыйфатлы чыгара. Тавышсыз эшли. Әмма төсле итеп чыгаручы принтер бик кыйммәт була шул. Хәзер принтерның нәкъ бу төрен күбрәк кулланалар.

Дускай, әгәр компьютерың бар икән, әти-әниеңнән принтер сорарга онытма. Ул сиңа киләчәктә дә кирәк булачак!

Әлегә шуларны исеңдә тот.

Очрашырбыз!



Рәссам Илдар НӘФИЕВ



Мин бит бу!





Айдар, 6 яшь
Айрат, 3 яшь

– Утынга барган идек,
Атыбыз ташлап качты!..

Яшел Үзән, Урысбага.

Инсаф, 1 яшь

– Үземчә хәл иттем әле –
Тәпи йөреп киттем әле!

Чирмешән.



Самат, 4 яшь
Адилә, 1 яшь

– Сусадык без белемгә –
Укый хәтта сеңлем дә!

Чистай, Гаделша.



Аделина, 5 яшь
Алинә, 1 яшь 6 ай

– Якты безнең карашыбыз...
Безне шулай яратыгыз!

Казан.



Регина, 3 яшь

– Камыр җәйим, дидем әле,
Әни эштән кайтканчы...

Сарман, Рангазар.

САЛАВАТ КҮПЕРЕ

БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ CHILDREN'S MAGAZINE

ИНДЕКС - 73953

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ» – сабыйлар журналы. Затлы, зиннәтле журнал!

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ» – халкыбызның күңел җәүһәрләрен - экият-хикәятләрен, такмак-такмазаларын, мәзәкләрен нәниләргә ирештерүче журнал!

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ» – татар әдипләренең балаларга атап язылсан иң гүзәл әсәрләрен сайлап дөньяга чыгаручы журнал!

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ» – сабыйларның экиятләрен, шигырьләрен, рәсемнәрен «ташка бастырып», нәни иҗатчыларны куандыручы журнал!

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ» – республиканың иң оста рәссамнарының сокландыргыч эшләренән сан саен бер күргәзмә ясаучы журнал!

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ» – балаларның кызыклы фотосурәтләрен бастырып, төрледән-төрле бәйгеләр оештырып, истәлекле бүләкләр белән шатландыручы журнал!

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ» – шәп журнал!

ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ӨЧЕН ИҢ ӘЙБӘТ ВАКЫТ!!!

